**8 нче сыйныфның татар теле дәресенә технологик карта**

| | | |
|---|---|---|
| **Тема** | Иярчен вакыт җөмлә. | |
| **Теманың максаты** | 1.Белем бирү: Иярчен вакыт җөмләләрне табу һәм аера белү.<br><br>2. Фикерләү сәләтен үстерү: укучыларның сөйләм телләрен, иҗади фикер йөртү сәләтләрен, танып-белү активлыгын һәм мөстәкыйльлекне , бәйләнешле сөйләм телләрен үстерү.<br><br>3. Тәрбияви: Кама ягы язучылары белән горурлану хисе, бер - берсенә ихтирамлылык, игътибарлылык тәрбияләү. | |
| **Планлаштырылган нәтиҗә** | Предмет күнекмәләре | Универсаль уку эшчәнлеге |
| **1.Предмет нәтиҗәләре**<br><br>**2.Метапредмет нәтиҗәләре**<br><br>**3. Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр** | 1. Иярчен вакыт җөмлә турында төшенчә формалаштыру, аның кулланылышын Ф.Бәйрамова әсәрләрендә тикшерү.<br><br>2. Иярчен вакыт җөмләләрне тану һәм аеру ысулларын билгеләү;<br><br>3. Укучыларда Ф.Бәйрамова әсәрләренә кызыксыну уяту. “Елга 50 китап”акциясенә кушылу. | Шәхси: Иҗади эшчәнлеккә омтылыш булдыру<br><br>Регулятив: Дәрестә өйрәнелгән материалның фәнне өйрәнүдәге, тормыштагы әһәмиятен ачыклау.<br><br>Танып – белү: матурлыкны күрә, аңлый белү<br><br>Коммуникатив: класс белән эшләгәндә классташлар фикерен исәпкә алып эш итү, күршең белән хезмәттәшлек итү. |
| **Төп төшенчәләр** | иярчен вакыт җөмлә. | |

| | | |
|---|---|---|
| **Предметара бәйләнешләр** | Әдәбият, матур әдәбият | |
| **Ресурслар**<br><br>**Җиһазлау:** | Төп: Зәкиев М.З., Максимов Н.В. Татар теле. Татар телендә урта<br><br>гомуми белем бирү мәктәбенең 8 нче сыйныфы өчен дәреслек,- Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2015. Өстәмә: презентация.<br><br>дәреслек, компьютер, индивидуаль карточкалар, сигнал карточкалары, интерактив такта, 8 нче сыйныф өчен татар теле дәреслеге | |
| **Төркемнәрне оештыру** | Төркемнәрдә, индивидуаль һәм парлы. | |

| **Дәрес этаплары** | **Дәрес этабының максатлары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Универсаль уку гамәлләре (УУГ)** |
|---|---|---|---|---|
| 1. Оештыру. Эшчәнлекне мотивлаштыру | Укытучы өчен максат: психологик уңай халәт барлыкка китерү | Укучыларда эшлисе килү халәте тудыру.<br><br>- Исәнмесез! Ягез,бер беребезгә елмаешып татар теле иленә сәяхәтебезне башлыйк.<br><br>Иң элек дәрескә булган кагыйдәләрне искә төшерик. | 1.Әдәпле һәм игътибарлы бул!<br><br>2.Сүзеңне ачык һәм дөрес әйт!<br><br>3Иптәшләреңне хөрмәт ит! | ШУУГ: үзмаксат кую<br><br>КУУГ: классташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Слайд№1.<br><br>Бу дәрестә сезнең белән катлаулы синтаксик күренешләрне аерым бер язучы иҗатында тикшереп карарбыз. | | |
| 2.Белем һәм күнекмәләрне формалаштыру | Укытучы өчен максат: ирчен җөмлә турында искә төшерү. | Укытучы: Без хәзер “Килешәсеңме?” уенын уйнарбыз.(сигнал карточкалары белән эш)(кушымта №1)<br><br>(сигнал карточкалар) | Укучылар сигнал карточкалар ярдәмендә үз фикерләрен дәлиллиләр. Кагыйдәләрне искә төшерәләр.<br><br>Нәтиҗә:1. Үзара ияртү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган җөмлә кушма җөмлә дип атала? 2.Мәгънә ягыннан иярчен кушма җөмләләр 12 төргә бүленә. | РУУГ: кагыйдә-ләрне истә тотып, гамәлләр кылу.<br><br>КУУГ: тыңлый белү, фикер алышуда катнашу. |
| 3.Дәрескә максат кую,белемгә омтылыш тәрбияләү | Өй эшен тикшерү.<br><br>Яратып укыган китап турында уй-фикерләрне язып килү. | | Укучының яратып укыган китабы турындагы хикәяне тыңлау. | ТБУУГ:фикерләүдә логик чылбыр төзү. |
| 4. Уку мәсьәләсен кую | Максат: иярчен вакыт җөмлә турында төшенчә бирү. | Укытучы өчен максат:иярчен вакыт җөмлә турында гомуми төшенчә бирү; аерым язучы иҗаты әсәрләреннән табарга | 1)Сәлимхан авылга кайткач, 2)өйләренә кергән ул аның.<br><br>Беренче җөмлә иярчен җөмлә, икенчесе баш җөмлә.Баш җөмләгә иярчен җөмлә өченче | РУУГ: үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, кагыйдәләрне истә тотып, гамәлләр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | өйрәтү.<br><br>Экранда җөмлә чыга. Укучылар тикшерә, анализлый.<br><br>Слайд№2<br><br>Тема чыгару:<br><br>Димәк, бүгенге дәреснең темасы ничек дип аталыр? | төр хәл фигыль кушымчасы – кач белән бәйләнгән.Баш җөмләдән чыгып, иярчен җөмләгә сорау куябыз. Ул кайчан? дигән сорау.<br><br>Нәтиҗә: 1.Бу мисалда беренче җөмлә икенче җөмләдән аңлашылган эшнең вакытын турыдан –туры белдерә.<br><br>Тема: Иярчен вакыт җөмлә. Эш дәфтәрләренә тема язалар. | кылу<br><br>КУУГ:иярчен вакыт җөмлә төзелешен искә төшерү |
| Уку мәсьәләсен адымлап чишү. | Максат: Ф.Бәйрамова әсәрләреннән иярчен вакыт җөмләләрне тикшерү. | Укытучы: Без бүген язучы Ф.Бәйрәмова әсәрләренә тукталырбыз. Әсәрләрдән алынган җөмләләрне тикшереп анализларбыз.<br><br>Слайд №3 | Җөмләләр бирелә:<br><br>1. 1)Билгеле бер вакыт җитү белән, 2)яфрак агачтан төшә.<br>2. 1)Шул кәгазьне алган көннән, 2)Кыяметдиннең тынычлыгы качты.3.1)Ташлар сыдырыла-сыдырыла аска төште, 2)шул чакта баш өстендә вертолет та күренде.<br><br>Укучылар нәтиҗә ясый: | ТБУУГ: уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү, төп билгеләрне<br><br>аерып алу нигезендә<br><br>кагыйдә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Дәреслек белән эш.<br><br>Укытучы: укучылар,без хәзер иярчен вакыт | Беренче җөмлә төзелеше ягыннан синтетик иярчен җөмлә. Мәгънәсе ягыннан ул иярчен вакыт җөмлә. Иярчен вакыт җөмлә баш җөмләгә –ү белән формасы аша бәйләнгән. Икенче җөмлә төзелеше ягыннан шулай ук синтетик иярчен җөмлә. Иярчен җөмлә кайчаннан? соравына җавап биреп, баш җөмләгә бәйлек сүз белән ияргән. Бу иярчен вакыт җөмлә. Өченче җөмлә төзелеше ягыннан аналитик иярчен җөмлә. Ул Кайчан? соравына җавап бирә.Иярчен вакыт җөмлә баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүз ярдәмендә ияргән.<br><br>Кагыйдәне укыйлар.<br><br>Үзбәя. Барлык җөмләләрне дөрес анализлаган кеше “5”ле,кем 1хата җибәргән”4”ле,кем 2 хата җибәргән”3”ле ала. | формалаштыру<br><br>КУУГ: үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү<br><br>РУУГ: үз эшчәнлегеңне контрольгә алу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | жөмләнең моделен ясап карыйк. | Тактада модель ясау.<br>Иярчен вакыт җөмлә<br>баш җөмләнең вакыт хәле урынында килә, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән вакыт хәлен ачыклый<br>кайчан? кайчаннан бирле? кайчанга чаклы? сорауларына җавап бирә<br><br>синтетик<br><br>аналитик<br><br>бәйләүче чара<br><br>бәйләүче чара<br><br>Ю.к.,У-в.к.куш-ры,<br>хәл фигыль куш-ры, | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Укытучы: ясалган нәтиҗә белән модельне чагыштырып карыйк. | бәйлекләр,<br>бәйлек сүзләр<br>мөнәсәбәтле сүзләр<br><br>Укучылар кабат укый, үз нәтиҗәләре белән чагыштыра.<br><br>Ял минуты (күзләр өчен гимнастика ясау) | |
| 5.Ныгыту | Белем һәм күнекмәләрне иҗади эштә файдалану. | 1төркемдә-4укучы; 2төркемдә-4укучы. Ике төркемгә дә Ф.Бәйрамова әсәрләреннән җөмләләр бирелә.<br><br>Бирем:<br>Карточкадагы җөмләләрне укып, һәр җөмләдә баш кисәкләрне, иярчен һәм баш | 1 төркем укучыларының чыгышы:<br><br>Икенче төркемдәге укучыларның чыгышы:<br><br>Гомуми нәтиҗә ясала: Әсәрләр язганда синтетик һәм аналитик төрдәге җөмләләрне куллану, язучы иҗатын тагын да баета.<br><br>Нәтиҗә: Ф.Бәйрамова иҗаты синтетик төр һәм аналитик | КУУГ: иҗади сәләтләрен үстерү<br><br>РУУГ: үзконтроль, биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | җөмләләрне, бәйләүче чараларны әйтергә. Схемаларын төзергә.<br><br>(Кушымта 2) | төр иярчен җөмләләргә бай икәненә инандык.<br><br>Укучылар белән нәтиҗә ясау: Иярчен вакыт җөмлә я баш җөмләнең вакыт хәле урынында килә, я баш җөмләдә мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән вакыт хәлен ачыклый. Ул, вакыт хәле кебек үк, кайчан? кайчаннан бирле? кайчанга чаклы? сорауларына җавап бирә.<br>(укучылар үз-үзләренә кабатлый һәм бер-берсенә әйтеп күрсәтәләр)<br><br>Үзбәя. | |
| 6.Рефлексия. Уку эшчәнлеген йомгаклау. | Алган белемнәрдән дөрес,урынлы итеп файдалана белү күнекмәләрен ныгыту. | Укытучы өчен максат:дәрестәге эшчәнлекне анализлау,белемнәрне бәяләү һәм киләчәккә перспектива билгеләү. | Сорау биреп, укучыларның белемнәрен тикшерү.<br><br>Укытучы: укучылар,без нинди тема белән таныштык? | ШУУГ: үз мөмкинлекләрең-не белү-белмәү чикләрен чамалау;<br><br>ТБУУГ: фикерләүдә логик |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Укучылар өчен максат:үз фикереңне дәлилләү, алган белемнәрне киләчәктә куллана белү<br><br>Укытучы:укучылар, йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: Ф.Бәйрәмова үз әсәрләрендә төзелеше ягыннан вакыт җөмләләрнең күп кенә вариантларын файдаланып, безнең күңелләргә үтеп керде. Мин сезне барыгызны да | Укучы җаваплары:<br><br>-Иярчен вакыт җөмлә<br><br>-Иярчен вакыт  җөмләләрне анализлап, бәйләүче чараларын белдек.<br><br>-Җөмләләрне Ф.Бәйрамова әсәрләреннән файдаландык.<br><br>-Язучының төзелеше ягыннан аналитик һәм синтетик җөмләләрне күп кулланганын күрдек.<br><br>Слайд4<br><br>Өй эше: 1)кагыйдәләрне өйрәнергә.2) Ф.Бәйрамова әсәрләреннән дәрестә кулланмаган җөмләләр табып язарга, тикшерергә һәм схемасын төзергә. | чылбыр төзү;<br><br>РУУГ: эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | “Елга 50 китап” акциясенә кушылырга чакырам.<br><br>Ә хәзер үзегезгә билгеләр куегыз. | | |

**Кушымта 1**

“Килешәсеңме?” уенын үткәрү (сигнал карточкалары белән эш)

1) Үзара ияртү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган җөмлә кушма җөмлә дип атала? (әйе)
2) Ияреп килгән җөмлә баш җөмлә була? (юк)
3) Аналитик җөмләнең бәйләүче чарасы хәбәр составында килми (әйе)
4) Мәгънә ягыннан ияртчен кушма җөмләләр 12 төргә бүленәләр (әйе)
5) Бәйләүче чара мөнәсәбәтле сүз булса, бу синтетик иярчен җөмлә була (юк)
6) Бәйләүче чара көттерү паузасы булганда ике җөмлә арасында ике нокта куела (әйе)
7) Барлык иярчен җөмләләрнең дә синтетик төре була (юк)

**Кушымта 2**

Бирем: Карточкадагы җөмләләрне укып, һәр җөмләдә баш кисәкләрне, иярчен һәм баш җөмләләрне, бәйләүче чараларны әйтергә. Схемаларын төзергә.

1 төркемгә

1.Урам Сталин исемен ишеткәнче,Кандыбин шабыр тиргә бата торган иде. 2.Поезд кузгалып киткәнче, Айсылу улын көтте. 3.Кышкы салкыннар башланганчы, алар барысы да җыелып, Мәккәгә кайтып та киттеләр.

2 төркемгә

1.Бала кайчан үсә,шул вакытта алардан бәреп торган кырыс салкынлык бераз басылыр. 2.Буран уйнап торган арада, Камил әбисеннән аерыла алмады. 3. Без ташларга сыдырыла-сыдырыла төшеп җиткәндә,баш өстендә вертолет та күренде.